**СОВЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422631с.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

---

**2024 елның 27 феврале** **211 номер**

**КАРАР**

**«Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау, һәм Рождествено авыл җирлеге муниципаль торак фонды йортларында социаль наем шартнамәсе буенча мондый гражданнарга торак урыннар бирү турында» 2011 елның 16 декабрендәге 50 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Граждан кодексы, "Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Рождествено авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау, һәм Рождествено авыл җирлеге муниципаль торак фонды йортларында социаль наем шартнамәсе буенча мондый гражданнарга торак урыннар бирү турында» 2011 елның16 декабрендәге 50 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр, ветераннар һәм яшьләр эшләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М. Гуцу**